**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 8 июлендәге 2381 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 30 мартындагы 946 номерлы**
**«Казан шәһәренең Физик культура һәм спорт комитеты карамагындагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә муниципаль йөкләмәгә кертелмәгән спорт чараларын яисә башка чараларны оештыруга һәм уздыруга субсидияләр бирүнең күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче һәм дүртенче абзацлары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертә торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 3985 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 30 мартындагы 946 номерлы «Казан шәһәренең Физик культура һәм спорт комитеты карамагындагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә муниципаль йөкләмәгә кертелмәгән спорт чараларын яисә башка чараларны оештыруга һәм уздыруга субсидияләр бирүнең күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карары кушымтасына, 2.7 пунктны түбәндәге

редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«2.7. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып, муниципаль биремгә кертелмәгән спорт яисә башка чараларны оештыру һәм уздыру, атап әйткәндә, спорт төрләрен популярлаштыру һәм үстерү, спорт осталыгын арттыру, иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, физик камилләшү өчен шартлар тудыру, физкультура-спорт хәрәкәтен саклау һәм үстерү тора.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатыннан чараның һәр төре өчен «Катнашучылар саны» күрсәткече билгеләнә:

- чемпионатлар һәм беренчелекләр – кимендә 20 кеше;

- кубоклар, спартакиадалар, турнирлар, лигалар, матчлар – кимендә 10 кеше;

-массакүләм спорт чаралары – кимендә 150 кеше;

- иҗтимагый киңлекләрдә уздырыла торган чаралар – кимендә 100 кеше;

- гомумшәһәр чаралары – кимендә 100 кеше;

- сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар – ветераннар катнашындагы чаралар – кимендә 2 кеше».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**